*Рәсимә Галиева,*

*филология фәннәре кандидаты,*

*Казан федераль университеты доценты*

# Беренче татар сатирик журналларын (“Карчыга”, “Чүкеч” һ.б.) өйрәнү мәсьәләләре

Югары уку йортында татар журналистикасы тарихын өйрәнгәндә аеруча зур игътибарны XX йөз башында чыккан сатирик журналларыбызга юнәлтү зарур.

Беренче рус революциясе тәэсирендә татар телендә басылган тәүге газет-журналлар белән беррәттән бер-бер артлы сатирик басмалар барлыкка килә. 1905-1906 еллар эчендә иң элек алты журнал чыга. Болардан дүртесе: “Чикерткә”, “Чүкеч”, “Карчыга”, “Яз” - Оренбургта, “Уклар” - Уральскида, “Туп” Әстерханда нәшер ителә. “Алдынгы демократик көчләр реакция елларында да сатирик матбугатны үткен караш коралы итеп файдаланырга омтылалар”, - дип яза Үзбәк Гыймадиев. 1908 елның августыннан 1909 елның июненә кадәр Казанда ун номеры чыгып калган “Яшен”, Тукай язганча, “...бөтен дөньяны кара кайгы болытлары каплаган” вакытта “күз камаштыра торган якты нурлары илә ялтырады”. 1910 елның мартында чыга башлаган “Ялт-йолт” гамәлдә “Яшен”нең дәвамы булды. 1918 елның июненә кадәр аның 123 номеры чыкты. 1911 елда Троицкида “Акмулла” журналы оештырыла һәм 1916 елның башында 50 нче санынннан соң туктала. Ниһаять, 1915 ел башыннан Оренбургта тагын бер сатирик журнал - “Кармак” чыга башлый һәм 1917 елның сентябренә кадәр 60 номеры дөнья күрә. Шулай итеп, 1906-1917 елларда татар телендә барлыгы ун сатирик журнал чыккан. Билгеле, Октябрьгә кадәрге сатирик матбугат болар белән генә чикләнми. 1909-1910 елларда “Казан мөхбире” газетасында “Без” исемле көлке

сәхифәләре (барлыгы 25 сан) биреп барыла. 1917 елның июленнән алып 1918 елның июненә кадәр Ташкентта татар телендә “Чаян” журналы (25 сан), 1917 елның декабреннән 1918 елның мартына кадәр Алма-Атада “Садак” журналы (5 номер) күбәйтеп таратыла. Шулай ук мәдрәсәләр дә алдынгы карашлы шәкертләр тарафыннан кулъязма сатирик журналлар чыгару тәҗрибәсе дә булган. Мәсәлән, 1905 елда Казандагы “Мөхәммәдия”мәдрәсәсендә “Ук”, һәм “Мылтык” исемле көлке журналлары чыгарыла. Уфаның “Галия” мәдрәсәсендә 1907 елда “Яшен” исемле сатирик журнал аваз сала. Шулай УК биредә “Парлак” (1913), “Бораү” (1917) исемле кулъязма сатирик журналлары дөнья күрә.

Югарыда без 1905 елдан башлап, нигездә, Октябрь революциясенә кадәр чыккан сатирик басмаларга күзәтү ясадык. Әлеге журналлар кайда гына чыгуга, нинди тематикага өстенлек бирелүгә карамастан озак яши алмыйлар. Журналлар шулкадәр көчле була ки, язмаларда үзләрен таныган явыз байлар, ялган муллалар әлеге басмаларны яптырырга йөри. Һәм ахыр чиктә журналлар чыкмый башлый. Мәсәлән, Җаектагы “Уклар” журналының нибары 6 саны гына чыгып кала. Ләкин икенче төбәктә, икенче җирлектә шул басмаларны, кайбер очракта авторлары да сакланып сатирик журналлар мәйданга килә. Сәбәпләренә тукталганда, иң элек аларның сатирик характерда булулары зур роль уйный.

Сатира социаль каршылыкларның, сыйнфый көрәшнең кискенләшкән чакларында аерата да үсә. Тормыштагы иске тәртипләргә каршы күтәрелгән прогрессив көчләр сатираны үзләренә корал итеп ала. Әлеге тарихи алшартлар татар телендә сатирик журналлар барлыкка килүгә этәргеч була. Журналлар гына түгел, чынбарлыкны сатирик сүрәтләү алымнары, жанрлар формалаша. Ләкин шул ук вакытта рус революциясе елларына кадәр булган сатирик иҗат тәҗрибәсен дә кире кага алмыйбыз. “Халык авыз иҗаты, аның жанр формалары, художество алымнары һәм чаралары сатирик журналларның башлангыч чорында да, аннары соңгы үсешендә дә җитди роль уйнаганнар. Мәкальләр, табышмаклар, такмаклар, такмазалар һәм

җырларның күбесеннән юмор чаткылары беркелеп тора. Әкиятләрдә һәм мәзәкләрдә исә сатира аеруча көчле. Аларда халыкның уй-тойгылары, изүчелергә, руханиларга, тормышның гарип күренешләренә нәфрәтле ироник карашы сәнгатьчә образлы төстә калку чагылган; гади халыкның зирәк акылы, тапкырлыгы, җор сүзе гәүдәләнгән". Татар әдәбиятының бай тарихын барлаганда да бик күп сатирик һәм юмористик алымнарны табарга мөмкин. "Карчыга" журналының нәшире һәм мөхәррире булган Шакир Мөхәммәдев иң элек үзен әдәбиятта сатирик әсәрләре белән таныта.

1905-1907 елларда берничә саннары гына чыгып калган "Уклар" (Уральск) һәм "Карчыга" (Оренбург) журналлары беренче сатирик басма үрнәге һәм татар сатирик журналистикасына нигез салучы булып тора. Биредә сатирик басма үз йөзендә формалаша. Беренче сатира жанрлары, сатирик тел һәм стилистик, образ тудыру чаралары барлыкка килә. Танылган сатириклар Г.Тукай һәм Ш.Мөхәммәдевлар бу журналларда үз каләменең көчләрен сыныйлар. Үз иҗатларына гына түгел, бербөтен сатира басмаларының тарихына нигез дә салалар.

Кайбер сатирик басмаларга Исмәгыйль Рәми һәм Рәис Даутов "Әдәби сүзлег"еннән күзәтү ясыйк әле.

"Чикерткә" - татар телендә нәшер ителгән беренче көлке журналларыннан. 1906 елның 23 апрелендә Оренбургта "Саранча" - "Чикерткә" исеме белән рус һәм татар телләрендә бер дәфтәргә төпләнеп чыга башлый. "Чикерткә" шуның татар телендәге өлеше. 36 битлек беренче санда татарча оригиналь текст 5 бит, икенче санда һәм дүртенчесендә алтышар бит тәшкил итә, өченче һәм бишенче саннары тоташ русча материалдан гыйбарәт. Журнал 1906 елның 22 октябрендә нәшер ителгән шул бишенче саныннан соң чыгудан бөтенләй туктый. Журналның гомум мөхәррире - Павел Александров дигән укытучы, татарча өлешендәге рәсемнәрен "Навайка" псевдонимлы һәвәскәр рәссам ясаган.

"Чүкеч" - 1906 елның июнь аеннан Оренбургта чыга башлаган һәм 1910 елның мартына кадәр дәвам иткән көлке журналы. Барысы 78 сан чыга.

Нәшире һәм мөхәррире - Тимерша Соловьев (1875-1947). 1906 елның октябреннән 1907 елның июленә кадәр журналга Мәхмут Алмаев мөхәррирлек итә. Берара Зариф Бәшири дә мөхәррир булып тора. Актив язылучыларга М.Алмаев, З.Бәшири, Н.Думави керә.

“Туп” - 1907 елның март-апрель айларында Әстерханда чыккан көлке журналы. Нәшире сәүдәгәр Иримбитов, рәсми мөхәррире - Хәбибулла Гомәрзадә (Гомәрев), асыл мөхәррире - Мәхмүт Галәү-Мәрҗани (ул елларда типографиядә хәреф җыючы), рәсемнәре мөгаллим Шәһит Бәйди (Гайфи) тарафыннан эшләнә. Журналның беренче саны таралып бетмәс борын конфискациягә эләгә, өченче саны да конфискацияләнгәч, журнал бөтенләй чыгудан туктый.

“Яшен” - юмор-сатира журналы. 1908 елның 3 августында чыга башлый. Журналның беренче санында Тукайның:

Ялтырый милли болытларның арасыннан “Яшен”

Бәлки, рәхмәт яңгырыдыр - яшьнәсен ул, яшьнәсен!

Юл табар золмәткә калганнар - төшерсен шәүләсен

Таш йөрәкләр һәм “яшен күргән укыр “Ләхәүлә”сен - дигән шигъри юллары белән ачыла. Соңыннан (1911-1912 елларда) шагыйрьнең ике кисәк булып чыккан “Яшен ташлары” китабына кергән көлкеләре башта шушы журналда басылганнар. Журнал барысы 10 сан чыгып, 1909 елның 24 июнендә туктала. Нәшире, мөхәррире һәм рәссамы - Г.Камал, басылуы Кәримовлар матбагасында иде.

“Ялт-йолт” - 1910 елның 15 мартыннан 1918 елның июненәчә Казанда чыккан көлке журналы. “Яшен” журналының дәвамы. Заманында юмор-сатира журналарыннан алдынгысы булып килде. Барысы 123 сан. Рәсми мөхәррире Әхмәт Урманчиев булса да, журнал тулысынча Г.Тукай, Г. Камаллар җитәкчелегендә чыкты дияргә була. Нәшире - “Юл” нәшрияты.

“Кармак” - 1915 елның 15 гыйнварыннан Оренбургта аена ике тапкыр чыга башлаган юмор-сатира журналы. Мөхәррире - Мәхмүт Мәрҗани (М.Галәү), “Белек” көтебханәсе. Журналны чыгаруда Шәехзадә Бабич,

Нәбир Бәкер, Шәриф Камал кебек танылган язучылар да катнашкан. Журналның яшәү дәвере беренче бөтендөнья сугышы барган авыр кичерешле, борчулы елларга туры килгәнгә, артык зур шөһрәт казана алмады. Журнал 1917 ел азагына 66 нчы саны чыкканнан соң тукталды.

Октябрьгә кадәрге сатирик матбугат татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә берничә булып чыга. Бит саннары, чыгу ешлыклары төрлечә һәм яшәү вакыты төрле елларга туры килсә дә, әлеге журналларны халык мәнфәгатьләре өчен яшәү идеясе берләштерә. Массаларны юк итергә, җәберләргә, каһәрләргә теләгән һәркем сатира угының узенә кадалачагын белә. Тормыштагы гаделсезлекләр, социаль каршылыклар, иҗтимагый-сәяси тормыштагы көлке хәлләрне журнал битләреннән табып укырга була. Сатирик журналлар иң элек яшәп килүче стройга, җәмгыятькә каршылык йөзеннән барлыкка килде. Әйтәсе фикерне сатира чараларына төрмичә әйтү ул чорда мөмкин эш булмый. Сатираның көче дә нәкъ аның эчке көчендә, каршылыгында чагыла. Автор әйтәсе килгән уй-фикерен төрле чаралар аша, төрле формаларга төреп укучыга җиткерә.

Татарча фикер йөртеп, аны сатира чаралары белән бирү татар укучысына икеләтә тәэсир иткәндер. Һәм бу табышның бәһасен журналны гамәлгә куючылар да, авторлар да яхшы аңлаган. Чөнки сатирик журналлар тел җәһәтеннән дә, журналдагы рәсем-иллюстрацияләр уңаеннан да татар журналистикасының башлангыч чоры өчен зур казаныш булып тора.

Журналистика фәнендә бүген гасыр башында чыккан сатирик басмаларның кыйбласын, тематик яктан үзенчәлеге ачылган хезмәтләр бар. Татар халкының фикер сөреше, вакытлы матбугатның киң мәйданга килүе, сатирик журналлар хакында М.Х.Гайнуллин, Р.У.Әмирханов; аерым татар сатирик басмаларның нәширләре, журналларның тематик ягын ачу, бәяләү мәсьәләсендә Ү.Гыймадиев хезмәтләрендә кызыклы фикерләр әйтелә. Алар әлеге журналларны тарихи яссылыкта күбрәк өйрәнәләр, беренче рус революциясе елларында татар сатирик журналларының нәшер ителү тарихын тикшереп, сәяси юнәлешләренә анализ ясый, социаль һәм милли

азатлык көрәшендә урыннарын билгелиләр. Шул ук вакытта әлеге басмаларда эшләгән аерым журналистлар эшчәнлегенә тукталган китаплар да чыкты. Сатирик журналистиканың жанрларына нигез салучы, күп журналларның мөхәррире, актив язышучысы булган Габдулла Тукай иҗаты бик күпләр тарафыннан өйрәнелде. Ибраһим Нуруллин, Рәфыйк Нәфигов кебек галимнәр Тукайның мирасын барлап, әйтәсе фикерләрен, карашларын анализладылар. Журналист буларак Тукайны журналистика теоретигы Флорид Әгъзамов та өйрәнә. Ләкин татар сатирик журналистикасында сатираның үсешендә зур роль уйнаган әлеге журналларның теле, нинди жанрда язылганлыгы тикшерелмичә кала. Журналлардагы бай мирас, төрле жанр һәм формаларда милләтебезнең үсү-үсеш процессын, яшәеш проблемаларын да чагылдыра. Басмаларда сатира теленең үзенчәлеге төрле жанр формаларында кулланыла. Шул ук вакытта узган гасыр башы сатирик журналистикасының тема һәм проблема үзенчәлекләре, авторлар составы, жанр төрлелеге, стиль, тел чаралары комплекслы рәвештә бүгенгә кадәр өйрәнелмәгән.

1905-1907 елларда чыккан сатирик басмалар алар, чыннан да, татар журналистикасына нигез ташларын салучылар булып торалар. Аларда эшләгән бөек шәхесләр бөек эшләре белән журналистикада үз эзләрен калдырдылар. Сатирик журналлар XX йөз башында татар журналистикасының үзенчәлекле бер тармагы буларак үсеш ала. Бер гасыр дәвамында төрле тарихи бәйләнеш-чишелешләр эчендә яшәсәк тә, XX гасырның икенче яртысында нәшер ителгән сатирик басмаларның тәэсир итү дәрәҗәсе беренчел журналлардан күпкә аерыла. Менә шул үзенчәлек беренче журналларны тематик, тел-стиль, жанр мәсьәләсе ягыннан да кабат өйрәнергә этәрә дә инде.

Укыту процессында беренче сатирик матбугатыбызның гаять бай тәҗрибәсен, эш алымнарын куллану булачак журналистларның осталыгын үстерүгә, һичшиксез, зур этәргеч бирә.